| | | |
|---|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.06.2021 № 126-П

г. Казань

Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган «Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексын (җитештерү корпусы бинасы, завод идарәсенең административ корпусы бинасы, транспорт цехы бинасы, ашханә)» ачыкланган мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) исемлегенә кертү турында.
Адрес: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2.

2002 елның 25 июнендә имзаланган № 73-ФЗ Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында», 2005 елның 1 апрелендә имзаланган № 60-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында», 2018 елның 12 июлендә имзаланган № 565 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» карары буенча боерам:

1. Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны -«Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексын (җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы)» ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә; Адрес: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2.

2. «Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексын (җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы)» территориаль барлыкка килгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен әлеге боерыкның 1нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. «Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексы (җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы

бинасы; ашханә бинасы)» ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын боерыкның 2нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Мәдәни
мирас объектларын саклау
комитеты рәисе вазифасын башкаручы Н. В. Прохорова.

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының
15.06.2021 №126-П
боерыгына 1 кушымта

«Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексы: җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы» мәдәни мирас объекты территориясе чикләре.

Адрес: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2.

«Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексы: җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы мәдәни мирас объекты территориясе чикләре картасы (схемасы)».

Адрес: «Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2




| | |
|---|---|
| **Масштаб 1:** | **500** |
| **Система координат :** | **МСК-16** |

**Условные обозначения:**

- ____ - существующая часть границы
- ____ - вновь образованная часть границы
- 16:50:011511- номер кадастрового квартала
- :59- номер земельного участка в кадастровом квартале
- ____ - зоны с особым условием использования
- ____ - граница кадастрового квартала
- ____ - граница объекта капитального строительства (сооружения)

**Условный номер земельного участка** ____________________

**Площадь земельного участка** **37687** **м$^2$**

«Спартак» аяк киеме фабрикасы бификасы биналары комплексы: җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы» мәдәни мирас объекты территориясе чикләре таблицасы. Адрес: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2.

| **Чикләрне билгеләү** | **Координаталары, м.** | |
|---|---|---|
| | **X** | **Y** |
| **1** | **2** | **3** |
| н1 | 474771.20 | 1305882.51 |
| н2 | 474637.07 | 1305952.15 |
| н3 | 474574.87 | 1306024.11 |
| н4 | 474579.51 | 1306027.98 |
| н5 | 474570.65 | 1306038.37 |
| н6 | 474551.97 | 1306066.88 |
| н7 | 474633.30 | 1306072.93 |
| н8 | 474710.83 | 1306137.70 |
| н9 | 474730.47 | 1306119.31 |
| н10 | 474730.93 | 1306119.69 |
| н11 | 474743.78 | 1306108.18 |
| н12 | 474786.55 | 1306062.96 |
| н13 | 474789.23 | 1306060.13 |
| н14 | 474790.27 | 1306058.98 |
| н15 | 474774.27 | 1306042.99 |
| н16 | 474818.02 | 1306000.03 |
| н17 | 474773.52 | 1305965.65 |
| н18 | 474789.60 | 1305944.63 |
| н19 | 474808.98 | 1305960.58 |
| н20 | 474813.61 | 1305954.69 |
| н21 | 474831.21 | 1305968.53 |
| н22 | 474842.95 | 1305955.68 |
| н23 | 474848.57 | 1305960.74 |
| н24 | 474868.06 | 1305938.80 |
| н25 | 474856.99 | 1305928.72 |
| н26 | 474857.46 | 1305928.20 |
| н27 | 474852.44 | 1305923.62 |

| | | |
|---|---|---|
| н28 | 474857.07 | 1305919.07 |
| н29 | 474846.56 | 1305908.37 |
| н30 | 474849.93 | 1305904.82 |
| н31 | 474849.42 | 1305904.34 |
| н32 | 474863.14 | 1305889.51 |
| н33 | 474860.54 | 1305886.97 |
| н34 | 474821.58 | 1305929.90 |
| н1 | 474771.20 | 1305882.51 |

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 15.06.2021 №126-П
боерыгына 2 кушымта

**Куллану режимы**
«Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексы: җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы» мәдәни мирас объекты территорияләре.
Адрес: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2.

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2 адресы буенча урнашкан «Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексы: җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы» мәдәни мирас объекты территорияләре чикләрендә **рөхсәт ителә:**

-мәдәни мирас объектының физик сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкару, шул исәптән консервация, ремонт, реставрация, заманча файдалануга яраклаштыру;

- мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килмәгән һәм мәдәни мирас объектының заманча шартларда эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;

- мәдәни мирас объектын, аның саклау предметын тәшкил итүче үзенчәлекләренә тимичә, функциональ файдалану төрләре нигезендә заманча файдалану һәм аларның җайлашуы;

- «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, мәдәни мирас объектының бөтенлеген боза торган корылмаларны һәм объектларны җимерү;

- гамәлдәге инженерлык инфраструктурасы объектларын (су белән тәэмин итү тышкы челтәрләре, канализация, җылылык белән тәэмин итү, газ, электр белән тәэмин итү, телефонизация һ.б.) капиталь ремонтлау, шулай ук башкарыла торган эшләр (шул исәптән динамик йогынты) мәдәни мирас объектына йогынты ясамау шарты белән инженерлык инфраструктурасының яңа объектларын җир астыннан салу;

- мәдәни мирас объектын саклап калуга, алардан файдалануга һәм популярлаштыруга юнәлтелгән территорияне төзекләндерү;

- мәйданчыкларны, юлларны түшәүдә традицион материаллар (кирпеч, таш, гранит һәм башка табигый материаллар, шулай ук табигый материалларны имитацияли торган материаллар) куллану;

- тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җиһазларын куллану;

- яшелләндерү: агачларны саклап калу, яшел үсентеләрне санитар кисү, яңа агачлар утырту;

- 2002 елның 25 июнендәге (“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары турында”гы № 73-ФЗ Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, аларны торгызу өчен җитәрлек фәнни мәгълүмат булган очракта, тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклау, мемориаль һәм архитектура-ансамбль объектлары (бина, корылма, кече архитектура формалары, койма, капка) югалган тарихи элементларны торгызу;

- мәдәни мирас объектының төп фасадында беренче каттан да югары итмичә мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру;

- 1992 елның 07 февралендәге “Кулланучылар хокукларын яклау турында”гы №2300-1 Федераль закон таләпләренә туры китерү өчен билгеләнгән тышкы мәгълүмат чараларын (элмә такта) урнаштыру: законнар нигезендә эшчәнлек профиле, оешманың фирма исеме, аның урнашкан урыны (адресы) һәм эш режимы, шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәве турында һәм аны теркәгән органның исеме турындагы мәгълүмат;

- тышкы мәгълүмат чаралары (элмә такталар) фриз биеклегеннең 2/3 өлешеннән артык булмаска тиеш, теге яки бу конструкцияне катлар белән тәрәзәләр арасына урнаштыру регламентлаштырылган;

-арка тәрәзәләре булганда, кат белән тәрәзә арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге ½ өлешкә кадәр кими. Мәгълүмати конструкцияләрнең киңлеге, декоратив-сәнгать панноларыннан тыш, теге яки бу корылманы урнаштыру стена киңлегенең 2/3 өлешеннән артмаска тиеш.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәни һәйкәлләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә үткәрелә.

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Спартак урамы, 2 адресы буенча урнашкан «Спартак» аяк киеме фабрикасы биналары комплексы: җитештерү корпусы бинасы; завод идарәсенең административ корпусы бинасы; транспорт цехы бинасы; ашханә бинасы» мәдәни мирас объекты территорияләре **чикләрендә тыела:**

- капиталь төзелеш объектларын төзү һәм һәйкәл яисә капиталь төзелеш объектларының ансамбле территориясендәге күләм-киңлек характеристикаларын арттыру; мәдәни мирас объектын яисә аның аерым элементларын саклап калу, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше яисә табигый мохитен саклау эшләреннән тыш, җир, төзелеш, мелиорация һәм башка эшләр башкару;

- мәдәни мирас объектының фасадларында һәм түбәсендә кондиционер, зур антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын урнаштыру;

- тышкы реклама чараларын урнаштыру;

- җир өстеннән инженерлык инфраструктурасы объектларын (су белән тәэмин итү тышкы челтәре, канализация, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, телефонизация һ.б.) үткәрү;

- элеккеләрен торгызудан тыш киоск, павильон, япма, кече архитектура формалар урнаштыру;

- мәдәни мирас объектына һәм аны әйләндереп алган корылмаларда динамик йөкләнеш тудыручы технологияләрне куллану;
- мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы төзелеш, көнкүреш калдыклары белән чүпләү;
- санитар кисүләрдән тыш агачларны кисү.